| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 ел. № 39

Олы Подберезье ав.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 12октябрендәге 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 3пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнеше чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %.».

1.2. 4 статьяда:

1.2.1. 4 абзацта «администрацияләр» сүзен «идарәче компанияләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«- «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзалары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәр белән никахта торучы ир яисә хатын;

2) хәрби хезмәткәрләрнең 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкәнрәк балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булган булсалар, шулай ук көндезге бүлектә белем алучылар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 10 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.2.2 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/bpberez-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М.Емельянова